ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Татарстан Республикасы Рәисе Вәкаләтле вәкилне билгеләп кую турында кабул ителгән карар хакында мондый карар кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр итә.»;

2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6 статья. **Вәкаләтле вәкилне вазыйфадан вакытыннан алда азат итү**

1. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре Татарстан Республикасы Рәисе карары белән түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:
1) вафат булса;
2) суд тарафыннан хокукка сәләтсез, хокукка сәләте чикләнгән яисә хәбәрсез югалган дип танылса йә вафат булган дип игълан ителсә;
3) аңа карата чыгарылган судның хөкем карары законлы көченә керсә;
4) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкса яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алса йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе

гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алса.

2. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештерелеп, Татарстан Республикасы Рәисе карары белән шулай ук түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

1) вәкаләтләрне туктату турында язма гариза бирсә;

2) медицина бәяләмәсе нигезендә билгеләнгән сәламәтлек торышы буенча яисә башка сәбәпләр белән озак вакыт дәвамында (кимендә дүрт ай) үз бурычларын үти алмаса;

3) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^{1}$ статьясында каралган очракларда ышанычны югалтса;

4) федераль законнарда билгеләнгән башка таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәсә.

3. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан шулай ук әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләрнең берсе буенча Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен туктату турында Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең тәкъдиме алынган очракта кабул ителә.

4. Татарстан Республикасы Рәисе Вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен туктату турында кабул ителгән карар хакында мондый карар кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр итә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 декабрь
№ 94-ТРЗ